ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮҢГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район д. Нижние Шаши. Тел. 3-60-38

КАРАР

11 ноябрь 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2022 елның 25 нче ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенынын үткәрү вакыты – 25 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;

үткәрү урыны – Күңгәр авылы, балалар уен мәйданчыгы каршында;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2022 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Шашы авылы, Молодежная урамы, 68 нче йорт;
- сайлау хокукына ия булган Күңгәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Күңгәр торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан,

мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;
- авыл территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрне чабу, чистарту), хезмәт өчен түләү.
- янгын гидранты һәм төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү (Ленин урамында -2 шт.,Советская урамында-1 шт.,К.Маркс урамында – 1 шт. гидрантлар урнаштыру)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә дигән
мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Шашы авылы, Яшьләр урамы 68 нче йорт адресы буенча стендка урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге
Советы 5 нче округ депутаты: Р.Х.Абдуллин